“Яңа ел хикмәтләре”

21 январь көнне мәдәният йорты хезмәткәрләре бәзәкәлелэрне күмәк чаңгыда шуарга чакырдылар. Табигать кочагында очрашу Яңа елда беренче тапкыр булгангамы, кышкы урманга сәяхәт бик күңелле узды. Рәхәтләнеп чаңгы шудык, шаярдык, көлдек, хәттә кайберләребез таудан “тәкәрләргә” дә җитеште. Иң кечкенә спорт сөючегә 7 яшь, ин өлкәне җиденче дистәне ваклаучы булуына да карамастан, барыбыз да бу сәяхәттән бик канәгать калдык. Туган ягыбызның табигате бик матур шул безнең! Шифалы саф һавасын сулап, купме яңа энергия алдык, көч тупладык, тәннәребез җаннарыбызны сафландырдык. Очрашуыбызның максаты да, хикмәте дә нәкъ менә шунда бит!

Г.Гөмәрова.















